КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 26 декабрь г.Казань № 1420

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2025 елларга «Татарстан Республикасы граждан-нарына социаль ярдәм күрсәтү» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 23 декабрь, 1023 нче карары белән расланган 2014 – 2025 елларга «Татарстан Республикасы граждан-нарына социаль ярдәм күрсәтү» дәүләт программасының 2014 – 2025 елларга «Татарстан Республикасы халкына социаль хезмәт күрсәтүне модер-низацияләү һәм үстерү» ярдәмче программасына 5 нче кушымтага үзгәреш кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2025 елларга «Татарстан Республикасы гражданнарына социаль ярдәм күрсәтү» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 23 декабрь, 1023 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 22 апрель, 267 нче; 2014 ел, 14 ноябрь, 876 нчы; 2014 ел, 12 декабрь, 977 нче; 2015 ел, 8 апрель, 231 нче; 2015 ел, 19 май, 358 нче; 2015 ел, 1 июнь, 396 нчы; 2015 ел, 16 июнь, 442 нче; 2015 ел, 2 ноябрь, 831 нче; 2016 ел, 24 февраль, 112 нче; 2016 ел, 15 апрель, 225 нче; 2016 ел, 8 май, 288 нче; 2016 ел, 22 июль, 498 нче; 2016 ел, 23 сентябрь, 681 нче; 2016 ел, 30 ноябрь, 884 нче; 2016 ел, 30 декабрь, 1053 нче; 2017 ел, 3 февраль, 59 нчы; 2017 ел, 26 май, 308 нче; 2017 ел, 21 июнь, 411 нче; 2017 ел, 26 июнь, 433 нче; 2017 ел, 10 октябрь, 777 нче; 2017 ел, 15 декабрь, 993 нче; 2017 ел, 29 декабрь, 1077 нче; 2018 ел, 19 гыйнвар, 18 нче; 2018 ел, 14 февраль, 87 нче; 2018 ел, 26 апрель,

285 нче; 2018 ел, 4 май, 318 нче; 2018 ел, 26 июнь, 519 нчы; 2018 ел, 22 сентябрь, 824 нче; 2018 ел, 24 декабрь, 1210 нчы; 2019 ел, 16 гыйнвар, 13 нче; 2019 ел, 2 апрель, 258 нче; 2019 ел, 22 июль, 612 нче; 2019 ел, 22 июль, 612 нче; 2019 ел, 17 сентябрь, 840 нчы; 2019 ел, 28 октябрь, 965 нче; 2019 ел, 12 ноябрь, 1035 нче; 2019 ел, 10 декабрь, 1134 нче; 2020 ел, 3 апрель, 254 нче; 2020 ел, 8 август, 668 нче; 2020 ел, 25 ноябрь, 1064 нче; 2020 ел, 8 декабрь, 1114 нче; 2020 ел, 11 декабрь, 1125 нче; 2020 ел, 18 декабрь, 1151 нче; 2021 ел, 12 март, 125 нче; 2021 ел, 27 март, 175 нче; 2021 ел, 21 июнь, 487 нче; 2021 ел, 6 ноябрь, 1052 нче; 2021 ел, 6 декабрь, 1166 нчы; 2021 ел, 20 декабрь, 1254 нче; 2022 ел, 19 март, 248 нче, 2022 ел, 23 май, 482 нче, 2022 ел, 3 октябрь, 1058 нче, 2022 ел, 20 декабрь, 1376 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган 2014 – 2025 елларга «Татарстан Республикасы гражданнарына социаль ярдәм күрсәтү» дәүләт программасының 2014 – 2025 елларга «Татарстан Республикасы халкына социаль хезмәт күрсәтүне модернизацияләү һәм үстерү» ярдәмче программасына 5 нче кушымтага, аны яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итеп, үзгәреш кертергә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

2014 – 2025 елларга «Татарстан Республикасы халкына социаль хезмәт күрсәтүне модернизацияләү һәм үстерү» ярдәмче программасына 5 нче кушымта
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2022 ел, 26 декабрь, 1420 нче
карары редакциясендә)

2023 елда Татарстан Республикасы территориясендә тәрбиягә мохтаҗ өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны озак вакыт тәрбияләү системасының үрнәк моделендә каралган максатлар һәм бурычлар нигезендә, тәрбиягә мохтаҗ өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны озак вакыт тәрбияләү системасын булдыру буенча чаралар планы («юл картасы»)

| Т/с | Чара исеме/ контроль нокталары | Җаваплы башкаручы | Документның көтелә торган нәтиҗәсе/төре | Гамәлгә ашыру срогы | | Финанслау һәм чыганаклар, мең сум |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | башлану вакыты | тәмамлану вакыты | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
| 1. Тәрбиягә мохтаҗ өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны озак вакыт тәрбияләү системасының үрнәк моделендә каралган бурычларны гамәлгә ашыруны тәэмин итү максатларында әзерләү чаралары | | | | | | |
| 1.1. | Татарстан Республикасында 2023 елда өлкән яшьтәге гражданнар һәм тәрбиягә мохтаҗ инвалидларны озак вакытлы тәрбия системасының Үрнәк моделе нигезендә озак вакытлы тәрбия системасын булдыру буенча пилот проектын (алга таба - пилот проекты, Үрнәк моделе, ОВТС) гамәлгә ашыру турында карар кабул итү, шул исәптән түбәндәгеләрне раслау (актуальләш- | ТР МК, ТР Хезмәт министрлыгы* | ТР МК карары | 2022 елның декабре | 01.03.2023 | Агымдагы финанслау |

*Файдаланылган кыскартылмалар исемлеге – 14 биттә.

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | терү):<br>Татарстан Республикасында гамәлгә ашырыла торган озак вакыт тәрбияләү системасы модельләре (алга таба - Төбәк моделе);<br>озак вакыт тәрбияләүнең социаль пакетына кертелә торган тәрбия буенча социаль хезмәтләр исемлеге;<br>озак вакыт тәрбияләүнең социаль пакетына кертелә торган социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибе;<br>озак вакыт тәрбияләү буенча социаль хезмәт күрсәтүләрнең социаль пакетына кертелә торган бердәм стандартлар | | | | | |
| 1.2. | ОВТС төзү буенча пилот проектын гамәлгә ашыру өчен Татарстан Республикасында җаваплы вазыйфаи затлар исемлеген актуальләштерү (кирәк булганда) | ТР Хезмәт министрлы-гы, ТР ССМ | ТР Хезмәт министрлыгының һәм ТР ССМ актуальләштерелгән уртак боерыгы | 2022 елның декабре | 01.03.2023 | Агымдагы финанслау |
| 1.3. | ОВТС төзү буенча пилот проектын гамәлгә ашыру буенча ведомствоара эш төркеменең эш тәртибен һәм составын актуальләштерү (кирәк булганда) | ТР МК, ТР Хезмәт министрлыгы | ТР МК боерыгы | 2022 елның декабре | 01.03.2023 | Агымдагы финанслау |
| 1.4. | Татарстан Республикасы хокукый актларын Үрнәк модель һәм Төбәк моделендә каралган максатларга һәм бурычларга туры китерү (раслау, актуальләштерү), атап әйткәндә:<br>гражданның социаль хезмәт | ТР Хезмәт министрлыгы | ТР Хезмәт министрлыгы боерыклары | 2022 елның декабре | 01.03.2023 | Агымдагы финанслау |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | күрсәтүгә, шул исәптән карау буенча социаль хезмәтләргә индивидуаль ихтыяҗын билгеләү кагыйдәләре;<br>гражданның социаль хезмәт күрсәтүгә, шул исәптән карау буенча социаль хезмәтләргә индивидуаль ихтыяҗларын билгеләү өчен сораштыру-анкета рәвешләре;<br>гражданның социаль хезмәт күрсәтүгә, шул исәптән карау буенча социаль хезмәтләргә индивидуаль ихтыяҗын билгеләү өчен сорашып белешү-анкета тутыру кагыйдәләре;<br>гражданга өйдә социаль хезмәт күрсәтү рәвешендә түләүсез бирелә торган озак вакыт тәрбияләү буенча социаль хезмәтләр күрсәтү турында хисап формалары;<br>тернәкләндерүнең техник чаралары прокаты пункты, тернәкләндерүнең техник чаралары исемлеге турында нигезләмәләр;<br>«Тәрбия мәктәбе» турында нигезләмәләр;<br>көндезге булу бүлеге (төркеме) турында нигезләмәләр (тәкъдим ителә торган җиһазлар исемлеген, җиһазлауны теркәп);<br>төбәк координация үзәге турында нигезләмә. | | | | | |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | РРҮ ДКУ төбәк координация үзәге функцияләрен йөкләү | | | | | |
| 1.5. | Ведомствоара хезмәттәшлек регламентын, шул исәптән мәгълүмати, ОВТС катнашучыларын, Үрнәк моделен исәпкә алып, актуальләштерү (кирәк булганда) | ТР МК, ТР Хезмәт министрлыгы | ТР МК карары проекты | 2022 елның декабре | 01.03.2023 | Агымдагы финанслау |
| 1.6. | Төбәк координация үзәге гамәлгә ашыра торган ОВТС эшчәнлеген мониторинглау тәртибен раслау | ТР Хезмәт министрлыгы | ТР Хезмәт министрлыгының һәм ТР ССМ уртак боерыгы | 2022 елның декабре | 31.12.2022 | Агымдагы финанслау |
| 1.7. | ОВТС гамәлгә кертү нәтиҗәләрен чагылдыра торган төп күрсәткечләрне раслау | ТР Хезмәт министрлы-гы, ТР ССМ | ТР Хезмәт министрлыгының һәм ТР ССМ уртак боерыгы | 2022 елның декабре | 01.03.2023 | Агымдагы финанслау |
| 1.8. | Озак вакыт тәрбияләүнең социаль пакетына кертелгән тәрбиягә, социаль хезмәт күрсәтүләргә мохтаҗ өлкән яшьтәге гражданнарга һәм инвалид-ларга бирү сыйфатын тикшереп тору-ны гамәлгә ашыру тәртибен раслау | ТР Хезмәт министрлыгы | ТР Хезмәт министрлыгы боерыгы | 2022 елның декабре | 01.03.2023 | Агымдагы финанслау |
| 1.9. | Билгеләү:<br>ОВТС катнашучылары булган социаль хезмәт күрсәтү оешмалары (социаль хезмәт күрсәтүләр белән тәэмин итүчеләр), медицина оешмалары исемлеге; | ТР Хезмәт министрлы-гы, ТР ССМ | ТР Хезмәт министрлыгының һәм ТР ССМ уртак боерыгы | 2022 елның декабре | 01.03.2023 | Агымдагы финанслау |
| | «Тәрбия мәктәбе»;<br>ТСР прокаты пунктлары;<br>көндезге тору бүлекләре (төркем-нәре) | ТР Хезмәт министрлыгы | ТР Хезмәт министрлыгы боерыгы | | | |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1.10. | ОВТС катнашучыларның ведомство-ара электрон хезмәттәшлеген бердәм мәгълүмат системасын камилләштерү, шул исәптән тәрбиягә мохтаҗ гражданнар турында мәгълүмат алмашуны да | ТР Цифрлы министрлыгы, ТР Хезмәт министрлыгы, ТР ССМ «РММАҮ» ДАССУ | тәрбиягә мохтаҗ гражданнар турында белешмәләр алуны, саклауны, тапшыруны һәм алмашуны тәэмин итүче «ТР СРН» ГМС «Озак вакытлы тәрбия системасы» актуальләштерелгән ярдәмче системасы (модуль) | 2023 елның гыйнвары | 31.12.2022 | Агымдагы финанслау |
| 2. Озак вакыт тәрбияләүнең социаль пакетына кертелгән тәрбиягә, социаль хезмәт күрсәтүләргә мохтаҗ гражданнарга бирүне оештыру чаралары | | | | | | |
| 2.1. | Төбәк һәм территориаль координация үзәкләре функцияләрен гамәлгә ашыру өлешендә РРҮ ДКУ Уставына үзгәрешләр кертү | ТР Хезмәт министрлыгы, РРҮ | РРҮ ГКУ Уставына үзгәрешләр, РРҮ ДКУ ОВТС координация бүлеге турында нигезләмә | 2022 елның гыйнвары | 31.12.2022 | Агымдагы финанслау |
| 2.2. | Төбәк һәм территориаль координация үзәкләре функцияләрен үтәү өчен РРҮ ДКУ штат расписаниесенә социаль эш буенча белгечләрнең штатлы берәмлекләрен кертү | ТР Хезмәт министрлыгы, РРҮ | РРҮ ДКУ штат расписаниесенә үзгәрешләр кертү | 01.04.2023 | 31.12.2023 | Агымдагы финанслау |
| 2.3. | Социаль хезмәтләр белән тәэмин итүчеләр базасында «Тәрбия мәктәбе» исемлеген төзү | ТР Хезмәт министрлыгы | ТР Хезмәт министрлыгы сайтында «Тәрбия мәктәбе» исемлеген урнаштыру | 2023 елның гыйнвары | 01.03.2023 | Агымдагы финанслау |
| 2.3.1. | Социаль хезмәтләр белән тәэмин итүчеләр базасында «Тәрбия мәктәбе» эшен оештыру | ТР Хезмәт министрлыгы, ХСХККҮ | 45 ХСХККҮ базасында «Тәрбия мәктәбе» эшли, өлкән | 2023 елның гыйнвары | 31.12.2023 | Агымдагы финанслау |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | яшьтәге һәм инвалидларның 300дән дә ким булмаган туганнары белем ала | | | |
| 2.4. | Социаль хезмәтләр белән тәэмин итүчеләр базасында ТТЧ прокаты пунктлары исемелеген төзү | ТР Хезмәт министрлыгы | ТР Хезмәт министрлыгы сайтында ТТЧ прокаты пунктлары исемлеген урнаштыру | 2023 елның гыйнвары | 01.03.2023 | Агымдагы финанслау |
| 2.4.1. | Социаль хезмәтләр белән тәэмин итүчеләр базасында ТТЧ прокаты пунктлары эшен оештыру | ТР Хезмәт министрлы-гы, СХКИ | 16 СХКИ базасында ТТЧ прокаты пунктларының эшләве | 2023 елның гыйнвары | 31.12.2023 | Агымдагы финанслау |
| 2.5. | Социаль хезмәтләр күрсәтүчеләр базасында көндезге бүлекләр (төркемнәр) эшен оештыру | ТР Хезмәт министрлы-гы, СХКИ | СХКИ базасында көндезге 50 бүлекнең (төркемнең) эшләве | 2023 елның гыйнвары | 31.12.2022 | Агымдагы финанслау |
| 2.6. | Социаль хезмәт күрсәтү дәүләт оешмалары (алга таба - социаль хезмәтләр күрсәтүче дәүләт оешмалары) эшен оештыру | | | | | Агымдагы финанслау |
| 2.6.1. | Социаль хезмәтләр белән тәэмин итүчеләр реестрын актуальләштерү | ТР Хезмәт министрлыгы | ТР Хезмәт министрлыгы сайтында социаль хезмәтләр белән тәэмин итүчеләрнең актуаль реестры | 2022 елның декабре | 31.12.2022 | Агымдагы финанслау |
| 2.6.2. | Социаль хезмәтләрне тәэмин итүчеләрнең штат санын карау буенча ярдәмчеләр белән тулыландыру | ТР Хезмәт министрлыгы | СХКИ штат расписаниесенә тәрбияләү буенча ярдәмчеләр кертү | 2023 елның апреле | 31.12.2023 | Агымдагы финанслау |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 2.7. | Социаль хезмәтләрне дәүләтнеке булмаган тәэмин итүчеләрне сайлау: | ТР Хезмәт министрлыгы | | | | Агымдагы финанслау |
| | 2023 елда озак вакыт тәрбияләү системасы кысаларында күрсәтелгән социаль хезмәтләр өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан компенсацияләр алуга | | ОВТС кысаларында социаль хезмәтләр күрсәтүче дәүләтнеке булмаган социаль хезмәтләр күрсәтүчеләр - сайлап алу җиңүчеләренең исемлеген күрсәтеп, социаль хезмәтләр күрсәтүгә бәйле рәвештә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр рәвешендә гранта бирү хокукына социаль хезмәтләр күрсәтүчеләр заявкаларын карау комиссиясе беркетмәсе | 2022 елның декабре | 01.02.2023 | |
| | 2021 - 2024 елларда «Сиделка» хезмәте күрсәтүгә бәйле рәвештә чыгымнарын финанс белән тәэмин итүгә юридик затларга, шәхси эшмәкәрләргә Татарстан Республикасы бюджетыннан 2023 елда субсидия бирүгә | | 2023 елда «Сиделка» хезмәтләр күрсәтүгә бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү хокукына сайлауда катнашуга заявкаларны карау һәм бәяләү | 2022 елның декабре | 01.02.2023 | |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | комиссиясе беркетмәсе, социаль хезмәтләр дәүләтнеке булмаган тәэмин итүчеләр, индивидуаль эшкуарлар - сайлап алуда җиңүчеләр исемлеген күрсәтеп | | | |
| 2.8. | Гражданның социаль хезмәт күрсәтүгә, шул исәптән региональ модель, мохтаҗлыкны бәяләү буенча экспертлар нигезендә социаль хезмәт күрсәтүләргә индивидуаль ихтыяҗларын билгеләүне (яңадан карауны) оештыру | ТР Хезмәт министрлыгы, РРҮ ДКУ, СХКИ | тәрбиягә мохтаҗлык дәрәҗәсен билгеләү максатында ОВТС кертелгән социаль хезмәтләр алучы 5 928 кешенең тәрбиягә ихтыяҗын яңадан карау | 2023 елның гыйнвары | 31.12.2023 | Агымдагы финанслау |
| 2.8.1. | Тәрбиягә мохтаҗ гражданнарның санын билгеләү | ТР Хезмәт министрлыгы | Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләре һәм тәрбиягә мохтаҗ булган өлкән яшьтәге гражданнар һәм инвалидлар саны турында хисап (фаразланган сан - 18 562 кеше) | 2023 елның гыйнвары | 31.12.2023 | Агымдагы финанслау |
| 3. Өйдә социаль хезмәт күрсәтү рәвешендә түләүсез тәрбияләүгә мохтаҗ гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү | | | | | | |
| 3.1. | Өйдә озак вакыт тәрбияләүнең социаль пакетына кертелә торган тәрбиягә, социаль хезмәт күрсәтүләргә мохтаҗ гражданнарга өйдә социаль хезмәт күрсәтү рәвешендә бушлай | социаль хезмәт күрсәтүләр белән тәэмин итүчеләр | озак вакыт тәрбия белән колачлау: 4 995 кешедән дә ким түгел (тәрбиягә мохтаҗлыкның | 2023 елның гыйнвары | 31.12.2023 | Агымдагы финанслау |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | бирү, шул исәптән: | | беренче дәрәҗәсе буенча - 3 241 кеше, икенче дәрәҗә буенча - 1 187 кеше, өченче дәрәҗә буенча - 567 кеше) | | | |
| | | | кимендә 364 кеше (тәрбиягә мохтаҗлыкның беренче дәрәҗәсе буенча - 78 кеше, икенче дәрәҗә буенча - 33 кеше, өченче дәрәҗә буенча - 253 кеше) | | | федераль бюджет акчалары - 70 759,1 мең сум;<br><br>Татарстан Республикасы бюджеты акчалары - 16 597,8 мең сум |
| 3.1.1. | социаль хезмәтләр күрсәтүче дәүләт хезмәтләре | СХКИ | 4 965 кешедән дә ким түгел (тәрбиягә мохтаҗлыкның беренче дәрәҗәсе буенча - 3 241 кеше, икенче дәрәҗә буенча - 1 187 кеше, өченче дәрәҗә буенча - 537 кеше) | 2023 елның гыйнвары | 31.12.2023 | Агымдагы финанслау |
| | | | кимендә 122 кеше (тәрбиягә мохтаҗлыкның беренче дәрәҗәсе буенча - 78 кеше, икенче дәрәҗә буенча | | | федераль бюджет акчалары - 15 866,8 мең сум;<br>Татарстан Республикасы бюджеты акчасы |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | - 33 кеше, өченче дәрәҗә буенча - 11 кеше) | | | – 3 721,8 мең сум; |
| 3.1.2. | дәүләткә карамаган социаль хезмәт күрсәтүләр белән тәэмин итүчеләр | дәүләткә карамаган социаль хезмәт күрсәтүләр белән тәэмин итүчеләр | кимендә 30 кеше (тәрбиягә мохтаҗлыкның өченче дәрәҗәсе буенча) | | | Агымдагы финанслау |
| | | | кимендә 242 кеше (тәрбиягә мохтаҗлыкның өченче дәрәҗәсе буенча) | | | федераль бюджет акчалары - 54 892,3 мең сум;<br><br>Татарстан Республикасы бюджеты акчалары - 12 876,0 мең сум |
| 4. Социаль хезмәт күрсәтүнең стационар оешмаларында социаль хезмәтләр күрсәтүне камилләштерү | | | | | | |
| 4.1. | Тәрбиягә мохтаҗ гражданнарга социаль хезмәтләр күрсәтелә торган стационар социаль хезмәт күрсәтү оешмалары исемлеген билгеләү | ТР Хезмәт министрлыгы | ТР Хезмәт министрлыгы боерыгы | 2022 елның декабре | 31.12.2022 | агымдагы финанслау |
| 4.2. | Тәрбиягә мохтаҗ социаль хезмәт күрсәтүләрне алучыларны карау буенча хезмәтләр күрсәтү | стационар СХКИ | кимендә 569 кеше | 2022 елның декабре | 31.12.2022 | агымдагы финанслау |
| 5. Әзерлек һәм өстәмә һөнәри белем бирү чаралары | | | | | | |
| 5.1. | Өстәмә һөнәри белем бирү программалары (квалификация күтәрү программалары) буенча карау буенча социаль хезмәт күрсәтүләрне оештыруда һәм күрсәтүдә катнашучы | РРҮ ДКУ | «Өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны өйдә социаль хезмәт күрсәтү шартларында | 2023 елның гыйнвары | 31.12.2023 | Агымдагы финанслау |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | социаль хезмәт күрсәтүчеләрнең дәүләт тарафыннан укытуны оештыру | | тәрбиягә мохтаҗ гражданнарны тәрбияләүне оештыру» программалары буенча квалификацияне күтәр (кимендә 16 академик сәгать, елга кимендә 100 хезмәткәр) | | | |
| 5.2. | Озак вакытлы тәрбия системасы эшчәнлеген тәэмин итүче социаль хезмәтләр күрсәтүче дәүләт хезмәткәрләре өчен өстәмә һөнәри белем бирү программалары (квалификация күтәрү программалары) буенча укытуны оештыру | РРҮ ДКУ | квалификация күтәрү программалары буенча квалификация күтәрү: «Тәрбия мәктәбе» стационар кулланыла торган технологияләрен гамәлгә ашыру кысаларында уку чаралары үткәрү (елына кимендә 34 академик сәгать күләмендә, елына кимендә 100 хезмәткәрне колачлау); «Өлкән яшьтәге гражданнар һәм инвалидларны стационар социаль хезмәт күрсәтү шартларында тәрбияләү буенча хезмәт күрсәтүләр оештыру | 2023 елның гыйнвары | 31.12.2023 | Агымдагы финанслау |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | һәм күрсәтү» (елына кимендә 16 академик сәгать күләмендә, елына кимендә 60 хезмәткәрне колачлау); «Гражданнарның социаль хезмәт күрсәтүгә индивидуаль ихтыяҗын билгеләү һәм озак вакыт тәрбиягә мохтаҗлык дәрәҗәсен билгеләү. Типлаштыруны оештыру» (кимендә 22 академик сәгать күләмендә, елына кимендә 100 хезмәткәр колачлый) | | | |
| 6. Контроль чараларны гамәлгә ашыру | | | | | | |
| 6.1. | Озак вакыт тәрбияләүнең социаль пакетына кертелгән тәрбиягә, социаль хезмәт күрсәтүләргә мохтаҗ гражданнарга бирү сыйфатына контрольне гамәлгә ашыру | РРҮ ДКУ, социаль хезмәтләр күрсәтүчеләр | ай саен хисап (муниципаль районнар, шәһәр округлары һәм социаль хезмәтләр күрсәтүчеләр киселешендә) һәм контроль чаралар үткәрү һәм аларның нәтиҗәләре турында мәгълүмати-аналитик белешмә | 2023 елның гыйнвары | 31.12.2023 | Агымдагы финанслау |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 6.2. | Озак вакытлы тәрбия системасы эшчәнлеген мониторинглау (мәгълүматны җыю, гомумиләштерү, анализлау һәм системалаштыру), шул исәптән: тәрбиягә потенциаль мохтаҗ гражданнарны ачыклау; гражданнарның социаль хезмәт күрсәтүгә, шул исәптән карау буенча социаль хезмәтләргә индивидуаль ихтыяҗын бәяләү; социаль хезмәтләр күрсәтүнең индивидуаль программасын, шул исәптән озак вакыт тәрбияләүнең социаль пакетын бирү өлешендә социаль хезмәтләр күрсәтүне тәэмин итүчеләр тарафыннан үтәүгә; ОВТС кертелгән гражданнарны карауны оештыру буенча медицина тәкъдимнәрен алу һәм үтәү | РРҮ ДКУ | ай саен хисап (муниципаль районнар, шәһәр округлары һәм социаль хезмәтләр күрсәтүчеләр киселешендә) мониторинг үткәрү һәм аларның нәтиҗәләре турында мәгълүмати-аналитик белешмә | 2023 елның гыйнвары | 31.12.2023 | Агымдагы финанслау |
| | Барысы | | | | | Барлыгы чаралар: 87 356,9 мең сум, шул исәптән:<br><br>Федераль бюджет чаралары - 70 759,1 мең сум;<br><br>Татарстан |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | Республикасы бюджеты акчалары 16 597,8 мең сум. |

Файдаланылган кыскартылмалар исемлеге:

«РММАҮ» ДАССУ – «Республика медицина мәгълүмат-аналитика үзәге» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе;

«ТР ХСР» ДМС - «Татарстан Республикасы халкының социаль регистры» дәүләт мәгълүмат системасы;

РРҮ ДКУ – «Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Республика ресурс үзәге» дәүләт казна учреждениесе;

ТР МК – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты;

ХСХККҮ – халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплекслы үзәге;

ТР ССМ – Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы;

ТР ЦМ – Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы;

ТР Хезмәт министрлыгы – Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы;

ТТЧ - тернәкләндерүнең техник чаралары;

СҮКУ - социаль хезмәт күрсәтү учреждениеләре.